

Съезд эшендә 33 РФ тобәгеннән 200гә якын кеше катнашкан. Шул исәптән Мордовиядән дә ике делегат корылтай эшендә катнашкан. Алар – Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе укытучысы Тәнзилә Юсиф кызы Секаева һәм Пензятка урта мәктәбе укытучысы Рауза Мокатдәс кызы Юмаева. Белгәнебезчә, укытучылар бу эшнен vзәгендә торалар, киләчәк буынга да жирле материалны житкерvче, кызыксындыручы һәм бала кvнелендә vз иленен патриот булу орлыклары салучылар да алар. Әлеге съезд Ботентатар тобәк тарихын ойрәнvчеләр жәмгыятенен оештыру чарасы. Бу жәмгыять, татарлар кvпләп яшәгән тобәкләрдә, филиаллары оештырылып эшләячәк дип котелә. Бvгенге кондә мондый филиаллар саны кырыкка якын. Жәмгыятьнен Советы сайланды, оператив мәсьәләләр хәл ителде бу корылтайда, дип хәбәр итте делегатлар. Анын составын ике елга бер мәртәбә янартып торылыр дип уйланылган. Тобәк тарихын ойрәнvчеләр жәмгыятенен журналы чыгачак. Анын исеме «Туган жир» («Родной край») булачак дип планлаштырыла. Әлеге басмада татар авыллары тарихына зур урын биреләчәк. Бvгенге кондә Россиядә 4300 исән татар авылы исәпләнә, беткән авыллар санын әле исәпләп чыгарган кеше юк. Интернетта татар авыллары тарихына багышланган Википедия кебегрәк ресурс булдыру турында да сvз алып барылды дип сойләделәр Мордовия делегатлары. Анда һәркем белгәннәрен язып барса, шулай кvмәкләп бу зур һәм әһәмиятле эш башкарылыр.

Съездда РФ тобәкләрендәге татар авыллары тарихына багышланган китаплар кvргәзмәсе белән танышканнар, ТФА Ш.Мәржани исемендәге тарих институты, Татар энциклопедиясе һәм тобәкне ойрәнv институты галимнәре катнашында «тvгәрәк остәлдә» тобәк тарихын ойрәнvнен һәм шул олкәдә жыелган мәгълvматларны практик яктан куллану турында сойләшкәннәр, «Донья тарихында Алтын Урда» («Золотая Орда в мировой истории») китабын тәкъдим итv кичәсе кызыклы vткән, «Ботентатар тобәк тарихын ойрәнvчеләр жәмгыяте»н съезднын пленар утырышында оештырылган, аннары - гомумтатар тобәк тарихын ойрәнvчеләр жәмгыяте Советы утырышы vткән, ТФА Ш.Мәржани исемендәге Тарих институты нәшер иткән хезмәтләр белән танышканнар, институт галимнәре белән очрашканнар һәм Г.Камал театрында кунакта да булганнар. Съезднын тыгыз программасы югары дәрәжәдә оештырылган булуы турында сойли.

**Н.Хәлил**